| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

3 август 2020 ел Буа шәһәре № 3-55

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү буенча Буа муниципаль районы Советының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 12 статьясы нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре», «Түбән Наратбаш авыл җирлеге», «Татар Буасы авыл җирлеге» һәм «Ырыңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан белдерелгән җирлекләр халкының ризалыгын исәпкә алып Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын закон чыгару инициативасы тәртибендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертергә һәм аңа материалларны.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законы проектын караганда Буа муниципаль районы Советы вәкиле итеп Буа муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Камартдиновны билгеләргә.

3. Буа муниципаль районы Советының 2019 елның 12 декабрендәге 1-48 номерлы «Буа муниципаль районы Советының «Буа шәһәре, «Түбән Наратбаш авыл җирлеге», «Татар Буасы авыл җирлеге» һәм «Ырыңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү буенча закон чыгару инициативасы турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет

мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru. адрес буенча урнаштырылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (рәисе А.М. Сибгатуллин) йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы урынбасары
Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Советы рәисе урынбасары И.Ф. Еремеев